ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы, 422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

31.10.2023 — с. Коргуза — 03

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 16 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2023 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2023 елның 16 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүлергә.

1 этап: Үзәк урам, Пролетар урамы, Сугыш урамы, Яшьләр урамы халкы.

2 этап: Беренче Май, Бакча, Октябрь урамы халкы.

3 этап: Заречная урамы, Яр буе урамы халкы.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Карагуҗа авылында авыл эчендәге юлларга вак җәю.

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Гражданнар җыеннарын үткәрергә:

1. 1 этап: Карагуҗа авылының Үзәк урамындагы кибет янындагы киселештә;
2. 2 этап: Карагуҗа авылының Үзәк мәйданы урамындагы мәктәп гаражы янында;
3. 3 этап: Карагуҗа авылы Яр буе урамындагы 15 нче йорт янында (А. И. Бочков).

7. Карагуҗа авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

8. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов